РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Елантовского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423597, Нижнекамский район,
с. Елантово, ул. Нагорная, 1г

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Елантау авыл җирлеге
Башкарма комитеты

423597, Түбән Кама районы,
Елантау авылы, Нагорная урамы, 1г

тел. /факс (8555) 33-30-42, электронный адрес: Elant.Nk@tatar.ru,
сайт: www. elantovskoe-sp.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.04.2021 ел № 4

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге Уставының 62 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешүләрне раслау хакында» 2020 елның 3 февралендәге 3 номерлы карарын игътибарга алып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлегендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 елның 2 июлендәге 8 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат такталарында халыкка җиткерергә һәм Елантау авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

В.А. Лебедев